СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
2015 елның 22 мае

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№525

2015 елның беренче кварталы өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында

«Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның 2015 елның беренче кварталы өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2015 елның беренче кварталы өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны исәпкә алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Совет рәисе** **А.В. Тыгин**

***Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондының акчаларын тоту турында белешмәләр 01.04.2015 ел торышы буенча***

| № т/б | Түләү максаты | Суммасы (сум) | Бюджет акчаларын алучы |
|---|---|---|---|
| 1 | Янгыннан зыян күрүчеләргә барлык матди ярдәм күрсәтү | 59 650,00 | ЗМР Башкарма комитет |
| 2 | Дәвалау өчен матди ярдәм күрсәтү, барлык матди ярдәмнең башка төрләре | 490 000,00 | ЗМР Башкарма комитет |
| 3 | «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр бөтендөнья оешмасының Евразия төбәк бүлеге» халыкара ассоциациясенең 2014 ел өчен еллык әгъзалык взносын түләү.". | 72 000,00 | ЗМР Советы |
| 4 | ЗМР волейбол буенча җыелма команда һәм актив әгъзаларына матди ярдәм түләү | 129 885,11 | ЗМР Башкарма комитет |
| 5 | Украина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясенә килгән Украина гражданына матди ярдәм күрсәтү | 37 771,00 | ЗМР Башкарма комитет |
| | **БАРЛЫГЫ** | **789 306,11** | |

ЗМР Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе О.П. Дёгтева